ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1030 «19 08 2016 ел

Архив эше өлкәсендә дәүләт
хезмәтләре күрсәтүнең
административ регламентларын
раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль архивлары гамәлгә ашыра торган дәүләт хезмәт күрсәтүләренең типовой административ регламентларын раслау турында» 08.06.2016 елның 8 июнендәге № 050-ОД Татарстан Республикасы Архив эше буенча Дәүләт комитеты боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Түбәндәгеләрне расларга (яңа редакциядә):

1.1. Дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив фондлары буенча архив белешмәләре, архив күчермәләре, архив документлары күчермәләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2. Дәүләт милкенә караган архив документларының кайда урнашуы мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты архив бүлегенең уку залында эшләү өчен кулланучыга дәүләт милкенә караган һәм муниципаль архивта саклана торган архив документларын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтәләр секторына өч эш көне дәвамында Татарстан Республикасы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырырп чыгагрырга.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 10 апрелендәге «Архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 472 номерлы карарын үз көчен югалтты дип таныргa.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.М.Дәрҗемановка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Ш.М. Сабиров